СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**Яңа Кишет авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**“16” октябрь 2019 ел** **№37**

**Яңа Кишет авыл җирлеге Советының “Физик затларның мөлкәтенә салым турында” 2015 елның 3 ноябрендәге 8 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, 2018 елның 3 августындагы 334-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Салым кодексының 52 статьясының беренче өлеше һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә Яңа Кишет авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. Яңа Кишет авыл җирлеге Советының 2015 елның 3 ноябрендәге 8 номерлы «Физик затларның мөлкәтенә салым турында» Карарына (Яңа Кишет авыл җирлеге Советының 2018 елның 29 ноябрендәге 16 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 карарның 2 пунктында:

1.1.1. 2 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2) 0,2 процент:
фатирга, фатирның өлешенә;
бүлмәгә карата;»;

1.1.2. 3нче пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«торак йортлар, торак йортларның өлешләре;».

2. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан физик затлар мөлкәтенә салымны исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан, игълан ителгән көннән бер ай үзганнан соң гына үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Арча хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Т.А.Арсланов